ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАС
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫН
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе а
422591

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

30.01.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-4 10

с. Введенская Слобода

## 2024нче елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370,20 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов

Введенский Бистәсе авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2024нче елның
30 гыйнварыннан 10 номерлы
карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегендә  2024нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре
01.02.2024 елдан

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4327,99 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1341,86 |
| 4. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,35 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Введенский Бистәсе авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2024нче елның 30
гыйнварыннан 10 номерлы
карарына

2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлегендә  2024нче елның 1нче февраленнән
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре
01.02.2024 елдан

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Тәнне төрү | 800,80 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3527,20 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1341,85 |
| 5. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,35 |
| Барлыгы | 8370,20 |